КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 17 июнь г.Казань № 467

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы; 2018 ел, 7 май, 327 нче; 2018 ел, 30 июль, 614 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1288 нче; 2019 ел, 23 апрель, 329 нчы; 2019 ел, 18 декабрь, 1165 нче; 2020 ел, 11 февраль, 87 нче; 2020 ел, 15 май, 392 нче, 2020 ел, 8 август, 666 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

беренче абзацта «2 317,8» саннарын «2 386,0» саннарына алмаштырырга;

икенче абзацта «621,9» саннарын «640,5» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «1 695,9» саннарын «1 745,5» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәдә:

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.2. Дәүләт комитеты үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне тормышка ашырганда:

гражданнар оборонасы өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү белән идарә итү (02.01.01[*]);

муниципальара һәм төбәк характерындагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә идарә итү (02.01.02[*]);

Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү белән идарә итү (02.01.03[*]);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән территориаль планлаштыру функциясен гамәлгә ашырганда (01.05.01[*]);

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән Төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.03.01[*]);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәт белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13[*]);

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02[*]);

Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасының ведомство дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.2 [*]);

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән тыш) (01.15.02[*]);

Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01[*]);

инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11[*]);

социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.1[*]);

Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.03[*]);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17[*]);

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы белән дәүләти-хосусый партнерлык һәм хосусый инвестицияләр, инвестиция проектларын тормышка ашыруны комплекслы алып бару өлкәсендә инвестиция эшчәнлеген үстерү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.10[*]).»;

4.2 пунктта:

4.2.3 пунктчага «, табигый дәвалау ресурсларын, дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны санитар (тау-санитария) саклауны тәэмин итү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген дә кертеп» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 4.2.17 пунктча өстәргә:

«4.2.17. Төбәк әһәмиятендәге махсус сакланылучы табигать территориясе чикләрендәге торак пункт территориясенә карата әзерләнгән җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектларын күрсәтелгән торак пункт территориясенә карата билгеләнә торган шәһәр төзелеше регламентының махсус сакланылучы табигать территорияләре турындагы Россия Федерациясе законнарында һәм махсус сакланылучы табигать территориясе турындагы нигезләмәдә каралган махсус саклау режимына туры килү предметына килештерә.»;

4.3 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Закон нигезендә Дәүләт комитетына башка вәкаләтләр йөкләнә, шул исәптән:

4.3.1. Дәүләт комитетының, эшчәнлекләре Дәүләт комитеты эшчәнлегенә бәйле яисә аны алып бару өлкәсендә булган оешмаларның мобилизацион әзерлеген һәм мобилизациясен оештыру һәм тәэмин итү, шулай ук әлеге чараларны методик озата бару;

4.3.2. Үз компетенциясе нигезендә федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары, башка Россия һәм чит ил органнары һәм оешмалары белән төзелгән шартнамәләр, килешүләр һәм башка гавами-хокукый характердагы актлар реестрын алып бару;

4.3.3. Ел саен, 1 февральгә кадәр, Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру буенча махсус дәүләт органына коррупциягә каршы сәясәт чараларын гамәлгә ашыру турында хисап тапшыру;

4.3.4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Дәүләт комитеты карамагына кертелгән мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү турында тәкъдимнәр әзерләү һәм кертү;

4.3.5. Гражданнарга дәүләт комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча телдән һәм язма рәвешләрдә хокукый консультация рәвешендә түләүсез квалификацияле юридик ярдәм күрсәтү Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибендә;

4.3.6. Социаль ярдәмгә һәм социаль яклауга мохтаҗ гражданнарга хокукый характердагы гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм башка документлар төзү рәвешендә бушлай квалификацияле юридик ярдәм күрсәтү, федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә судларда, дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда гражданнар мәнфәгатьләрен тапшыру;

4.3.7. Капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә региональ әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләре чикләрендә (1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында» Федераль законның $3^1$ статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш) реконструкцияләүне гамәлгә ашыру планлаштырыла торган төзелешкә рөхсәт бирү;

4.3.8. Төбәк әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләре чикләрендә төзелгән, реконструкцияләнә торган капиталь төзелеш объектларын ("Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында" 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның $3^1$ статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш) эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү;

4.3.9. Индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларын планлаштырыла торган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектын яисә индивидуаль торак төзелеше объектын төзегәндә, реконструкцияләгәндә җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын, региональ әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территориясе чикләрендәге бакча йортларын төзү, реконструкцияләү барышында ("Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында" 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның $3^1$ статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш) урнаштыру мөмкинлеге хакында хәбәрнамә юлламасы;

4.3.10. Индивидуаль торак төзелешенең яисә бакча йортының төзелгән яисә реконструкцияләнгән объектының индивидуаль торак төзелеше объектын, региональ әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территориясе чикләрендәге бакча йортларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамәнең ( «Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның $3^1$ статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш) юнәлеше;

4.3.11. Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.61 статьясында караллан административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүне башкара;

4.3.12. Тиешле рөхсәтсез саклаган яисә Татарстан Республикасы территориясендә табылган кораллар, сугыш кирәк-яраклары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрне үз ирекe белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләк бирүне гамәлгә ашырырга;

4.3.13. Ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт хокукы нормалары булган хезмәт законнарының һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешен ведомстволы тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

4.3.14. Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.».

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

әлеге карарның 1 нче пунктындагы икенче - бишенче абзацлары гамәле 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

әлеге карарның 1 пунктындагы кырык дүртенче, кырык бишенче абзацларының гамәле 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

әлеге карарның 1 пунктындагы кырык дүртенче абзацы 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 17 апрель, 298 нче карарын үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин